КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 9 август г.Казань № 638

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы икътисады белән индикатив идарә итү системасын гамәлгә ашыру чаралары турында» 2000 ел, 29 май, 371 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 ел, 04 декабрь, 589 нчы, 2009 ел, 12 март, 142 нче, 2009 ел, 23 март, 160 нчы, 2009 ел, 19 октябрь, 732 нче, 2013 ел, 25 июль, 522 нче, 2023 ел, 09 август, 962 нче карарлары кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы икътисады белән индикатив идарә итү системасы регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктта:

сигезенче абзацта «2030 елга кадәр чорга Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары турында» 2020 елның 21 июлендәге 474 номерлы» сүзләрен «2030 елга кадәр чорга һәм 2036 елга кадәр перспективага Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары турында» 2024 елның 7 маендагы 309 номерлы» сүзләренә, «17 июльдән» сүзләрен «17 июньнән» сүзләренә алмаштырырга;

тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«төбәк проекты - дәүләт программасы чараларының (нәтиҗәләренең) максатларына, күрсәткечләренә һәм гамәлгә ашырылуына ирешүне яисә өлеш кертүне, шулай ук Россия Федерациясе Президенты, Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе, Татарстан Республикасы Премьер-министры йөкләмәләре һәм (яисә) күрсәтмәләре буенча башка күрсәткечләргә ирешүне тәэмин итүче проект;»;

унынчы абзац үз көчен югалткан дип танырга;

3.3 пунктның дүртенче абзацында «һәм ведомство» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 15 май, 750-б номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 11 апрель, 857-б номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 23 ноябрь, 1499 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне

исәпкә алып) белән расланган Республика башкарма хакимият органнарына идарә итүгә йөкләмәне үтәү йомгаклары буенча республика башкарма хакимият органнары рейтингын формалаштыру методикасына, 2 пунктта «2030 елга кадәр чорга Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары турында» 2020 елның 21 июлендәге 474 номерлы» сүзләрен «2030 елга кадәр чорга һәм 2036 елга кадәр перспективада Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары турында» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин